РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

**№ 30/3** **2018 елның 2 феврале**

***Решение*** ***Карар***

Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәткә идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 04 октябрендәге 25/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 04 октябрендәге 25/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.1 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге катнашучы муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләр, шулай ук башка милек рәвешләрендәге оешмалар йөкләмәләрен;

1.2. 15.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.3. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибенең үтәлешен тикшереп тору контроль чаралар уздырганда Чистай муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Муниципаль милеккә идарә итү һәм аның белән эш итү өлешендә эчке контроль «Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турында» нигезләмәсе нигезендә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов